**БАШКАРМА КОМИТЕТ БОЛЬШЕРУСАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ УРСАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ТИПИК ПРОЕКТ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.06.2025ел Олы Урсак ав. № 5

«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитетының 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлеге бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» Олы Урсак авыл җирлегенең башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Субсидияләр биргәндә аларны бирүнең мәҗбүри шарты булып субсидияләр бирү турындагы шартнамәләргә (килешүләргә) һәм шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләргә (килешүләргә) керүче товарлар җитештерү (сату) , эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү турында шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча товар китерүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып торучы затларның һәм субсидия алучыларның (устав (тупланма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашкан дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашындагы коммерция оешмаларыннан тыш,) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пунктының 5 бүлегендә каралган тикшерүләрне муниципаль финанс контроле органнары - субсидия бирә торган бюджет акчаларының төп бүлүчесе - башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашыруга ризалыгы тора.».

2.Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб - адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми

порталы»нда həм https://bagaev-kaybici.tatarstan.ru/ веб - адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Олы Урсак авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчес вазыйфаларын башкаручы Нуреев Р.Х.